**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФОМА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

ОГРН 109166500037, ОКПО 60321874 , ОКАТО 92246888000,
ИНН/ КПП 1632011440/163201001, ОКТМО 92646488

Фома авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 15нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Спутник урамы 1-29нчы, Чапаев урамы 1-85нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 15нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Мәктәп урамы 1-53нче, Совет урамы 1-45нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Гагарин урамы, 20нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Тукая урамы 1-57нче, Яшьләр урамы 1-7нче, Гагарин урамы 1-37нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2019 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка К.Маркс урамы, 48нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Елга урамы 1-46нчы, К.Маркс урамы 2-90нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2019 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Дуслык урамы, 44нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Дуслык урамы 2-82нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. Гражданнар җыенын уздыру өчен Фома авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

7. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, 500 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт-вак таш җәю;
- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә карата тәэмин итү буенча эшләр башкару.

«ӘЙЕ» «ЮК».

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов